| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>14.02.2020 | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>№ 255 |

2020 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре тарафыннан җәмәгать эшләрен оештыру турында

«Россия халыкның эш белән тәэмин ителеше турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать эшләрен оештыру турында нигезләмә раслау хакында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы карарын үтәү йөзеннән, эшсезлекнең икътисади нәтиҗәләрен йомшарту һәм эшләмәүче халыкны вакытлыча эш белән тәэмин итү һәм өстәмә хезмәт хакы рәвешендә эшсез халыкны матди яктан тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елда Зеленодольск муниципаль районы территориясендә башкарыла торган җәмәгать эшләренең төп төрләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районының предприятие, учреждение һәм оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә (2 нче кушымта):

2.1. Зеленодольск шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә һәр айның 1 числосына кадәр җәмәгать эшләре күләме буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

2.2. Зеленодольск шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән шартнамәләр буенча җәмәгать эшләрен оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә;

2.3. җәмәгать эшләрен башкару өчен эш белән тәэмин итү хезмәте тарафыннан җибәрелгән гражданнарны эшкә урнаштыру һәм аларның хезмәтен үз вакытында түләү.

3. Зеленодольск шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә (С.В. Гататдиновага):

3.1. Зеленодольск муниципаль районы эш бирүчеләре тарафыннан игълан ителгән җәмәгать эшләренә эшсез гражданнарны оператив рәвештә җибәрүне тәэмин итү;

3.2. җәмәгать эшләрендә эшләүче эшсез гражданнарга матди ярдәм түләүләрен үз вакытында башкарырга.

4. Әлеге карарны ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына (Р.З. Хаҗиевка) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.З. Усмановка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма
комитетының
2020 елның 14 февралендәге
255 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ БАШКАРЫЛА ТОРГАН ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛӘРЕНЕҢ ТӨП ТӨРЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ**

- Авыл хуҗалыгы язгы чәчү - кыр эшләрен башкарганда сезонлы эшләр
- Торак-коммуналь хуҗалыкны эксплуатацияләү
- Төзекләндерү, тротуарларны һәм подъездга керү юлларын рәтләү
- Юл капламаларын пычрактан һәм кардан чистарту
- Төзелеш материаллары җитештерү
- Җыештыру, территорияләрне төзекләндерү һәм яшелләндерү
- Ярдәмче рәвешендәге эшләр
- Биналарга, корылмаларга хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эше
- Икенчел чималны һәм калдыкларны җыю һәм эшкәртү
- Янгыннан соң урманнарны торгызу (агачларны кисү, төпләү)
- Куакларны тигезләп кисү, үләннәрне чабу, территорияне чүп-чардан чистарту, чүп-чарны чыгару эшләре
- Шугалакларны су белән кою һәм кардан чистарту
- Яшелләндерү
- Квартал эчендәге территорияләрне һәм чүп-чар белән көнкүреш калдыклары булган контейнер мәйданчыкларын санитар чистарту
- Торак йортларның бүлмәләрен, баскыч мәйданчыкларын җыештыру
- Автобус тукталышларын төзекләндерү һәм җыештыру
- Автотранспорт юу
- Ягу сезонына әзерлек эшләре
- Архивларны (документларны архивка әзерләү эшләрен) оештыруда һәм әзерләүдә ярдәм итү
- Машина яздыру эшләрен башкару
- Гардеробта эшләү
- Савыт-саба юу
- Нәшриятларда ярдәмче эшләр башкару
- Матбугат басмаларын тарату
- Реклама тарату
- Документларны исәпкә алу һәм рәсмиләштерү
- Китапханә системасына хезмәт күрсәтү

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма
комитетының
2020 елның 14 февралендәге
255 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының җәмәгать эшләрен әзерләүдә һәм уздыруда катнашучы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар исемлеге**

1. «ТР ЗМР ТКХ департаменты» МБУ
2. «Жилкомплекс» идарәче компаниясе» ҖЧЖ
3. «Управдом +» ҖЧЖ
4. «ЭлиСС» ҖЧЖ
5. «Рубикон» ИК» ҖЧЖ
6. «Центр ТК» ҖЧЖ
7. «Уютный дом» ҖЧЖ
8. «Таиф" торак компаниясе» ҖЧЖ
9. «Респект» торак компаниясе» ҖЧЖ
10. «Бизнес-үзәк» ҖЧЖ
11. «Энергосервис - Н» ҖЧЖ
12. «Старт-3» ИК» ҖЧЖ
13. «ЕАДС» ТК» ҖЧЖ
14. «ЗПТС» АҖ
15. «ЗВКС» АҖ
16. «Сервис» МКД ҖЧЖ
17. «ЗЗСК» ҖЧЖ
18. «Металл конструкцияләр заводы" ҖЧЖ
19. «Грант»ҖЧЖ
20. «Торак-коммуналь хезмәт күрсәтү» ҖЧЖ
21. «Нижневязовская жилкомсервис» ҖЧЖ
22. «Торак компаниясе» ҖЧЖ
23. «Норлат ТКХ МПП» МУП
24. «Коммуналь хуҗалык" МУП
25. «Күгәй» АХҖК
26. Васильево ш.т.п. БК
27. Карамалы Тау бистәсе ш.т.п. БК
28. Әйшә авыл җирлеге БК
29. Акзъегет авыл җирлеге БК
30. Олы Ачасыр авыл җирлеге ИК
31. Большие Ключи авыл җирлеге БК
32. Олы Шырдан авыл җирлеге БК
33. Олы Җәке авыл җирлеге БК
34. Бишнә авыл җирлеге БК
35. Олы Карагуҗа авыл җирлеге БК

36.Күгеш авыл җирлеге БК
37.Күгәй авыл җирлеге БК
38.Мамадыш-Әкил авыл җирлеге БК
39.Мулла Иле авыл җирлеге БК
40.Түбән Урысбага авыл җирлеге БК
41.Норлат авыл җирлеге БК
42.Октябрь авыл җирлеге БК
43.Осиново авыл җирлеге БК
44.Раифа авыл җирлеге БК
45.Рус Әҗәле авыл җирлеге БК
46.Зөя авыл җирлеге БК
47.Өтәшкә авыл җирлеге БК
48. «Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ
49.ЗМР БК мәгариф идарәсе учреждениеләре
50.ЗМР БК Мәдәният идарәсе учреждениеләре